| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ЛЕНИНОГОРСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>«ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

26.03.2021 г.Лениногорск № 18

Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» Советының 2013 елның 26 апрелендәге 25 номерлы карары белән расланган Лениногорск муниципаль районында муниципаль торак фондының торак урыннарына социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарны аз керемлеләр дип тану һәм аларга муниципаль торак фондының торак урыннарына социаль наем шартнамәләре буенча бирү максатларында һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнәр күләмен һәм алар милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында «Татарстан Республикасы Законының 10 һәм 25 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 4 сентябрендәге 53-ТРЗ номерлы ТР Законы нигезендә Лениногорск муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» Советының 2013 елның 26 апрелендәге 25 номерлы карары белән расланган Лениногорск муниципаль районында муниципаль торак фондының торак урыннарына социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарны аз керемлеләр дип тану һәм аларга муниципаль торак фондының торак урыннарына социаль наем шартнамәләре буенча бирү максатларында һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнәр күләмен һәм алар милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 пунктның «ж» подпунктындагы 2 абзацта «Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының җинаять башкарма системасы» сүзләреннән соң

тулыландырырга;

2 пунктның «ж» подпунктындагы 3 абзацта «Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының җинаять-башкарма системасы» сүзләреннән соң «,Россия Федерациясе мәҗбүри үтәү органнары» сүзләре белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны рәсми публикатор – “Лениногорские вести” газетында бастырырга, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://Ieninoqorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе З.Г. Михайловага йөкләргә.

Лениногорск муниципаль
районы Башлыгы,
Совет рәисе Р.Г.Хөсәенов